КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 1 февраль г.Казань № 62

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан эш бирүчеләрдә инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын резервка алу тәртибен раслау турында» 2007 ел, 18 май, 194 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан эш бирүчеләрдә инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын резервка алу тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан эш бирүчеләрдә инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын резервка алу тәртибен раслау турында» 2007 ел, 18 май, 194 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 31 декабрь, 1196 нчы, 2014 ел, 20 май, 334 нче; 2015 ел, 18 июль, 524 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан эш бирүчеләрдә инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын резервка алу тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктта:

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«пенсия алды яшендәге гражданнар (картлык буенча хезмәт пенсиясенә, шул исәптән картлык буенча алдан билгеләнә торган хезмәт пенсиясенә чыгу хокукын алуга биш ел кала);»;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«урта һөнәр белеме бирү учреждениеләрен тәмамлаучылар арасыннан 18 яшьтән 25 яшькә кадәрге беренче тапкыр эш эзләүче гражданнар;»;

3.1 пунктның өченче абзацында «тернәкләндерүнең» сүзләреннән соң «яки абилитация» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин